РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Какре-Елгинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. Советская, д. 22, Азнакаевский район,
с.Какре-Елга, 423320,
тел./факс (885592)37-0-49
E-mail: Kelg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге
башлыгы

Совет ур., 22 йорт, Азнакай районы,
Кәкре Елга авылы, 423320
тел./факс (885592)37-0-49
E-mail: Kelg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «07» март 2024 ел.** **№ 1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл торак пунктында гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 08 ноябрендәге 2 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 08 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясына ярашлы, муниципаль берәмлек башлыгы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пунктында:«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл торак пунктында гражданнар җыены

нәтиҗәләре турында» 10.11.2023 № 2, «2024 елда Якты Юл пунктында гражданнарның үзара салым кертү турында» 10.11.2023 № 1 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 18 мартына 09.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында «2023 елның 08 ноябрендәге 1 номерлы, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юл торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында гражданнар җыены карарларына” үзгәрешләр кертергә ризамы:

«1) Якты Юл торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (тракторчыга механизацияләнгән кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү),

2) су белән тәэмин итү һәм суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм тоту, контракт буенча эш өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, труб) Якты юл торак пунктында).

«ЭЙЕ» «КАРШЫ».

3 Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatar.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районының Кәкре Елга җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы И.М.Мөхәмәтҗанов